МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.04.2024 Казан ш № 240

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Баланың тууы һәм аны тәрбияләүгә бәйле рәвештә айлык пособие бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2023 елның 15 мартындагы 170 номерлы боерыгы белән расланган Баланың тууы һәм аны тәрбияләүгә бәйле рәвештә айлык пособие бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Баланың тууы һәм аны тәрбияләүгә бәйле рәвештә айлык пособие бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2023 елның 15 мартындагы 170 номерлы боерыгы белән расланган Баланың тууы һәм аны тәрбияләүгә бәйле рәвештә айлык пособие бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне (алга таба – Үзгәрешләр) расларга.Р31

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә, дип билгеләргә, Үзгәрешләрнең дүртенче, бишенче, сигезенче, уникенче, алтмыш дүртенче абзацлары искәрмә булып тора, алар 2024 елның 1 июнендә үз көченә керә, Үзгәрешләрнең унөченче-унҗиденче, алтмыш өченче, җитмеш җиденче-сиксән җиденче абзацлары 2024 елның 5 августында үз көченә керә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 02.04.2024 ел, № 240 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Баланың тууы һәм аны тәрбияләүгә бәйле рәвештә айлык пособие бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2023 елның 15 мартындагы 170 номерлы боерыгы белән расланган Баланың тууы һәм аны тәрбияләүгә бәйле рәвештә айлык пособие бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм платформа» дәүләт мәгълүмат системасы составына керүче «Гражданнар белән үзара хезмәттәшлекнең бердәм контакт-үзәге» мәгълүмат системасы аша»;

14 пунктта:

беренче абзацта «айлык пособие билгеләү турында» сүзләреннән соң («Балалары булган гражданнарга дәүләт пособиеләре турында» федераль законда билгеләнмәгән өлештә 2330 номерлы карар белән расланган Бала тууга һәм аны тәрбияләүгә бәйле рәвештә айлык пособиене билгеләү һәм түләү кагыйдәләренең (алга таба – Кагыйдәләр) 65 пунктында каралган очрактан тыш»)) сүзләрен өстәргә;

икенче абзацта «айлык пособие билгеләү турында» сүзләреннән соң «(Кагыйдәләрнең 65 пунктында каралган очрактан тыш)» сүзләрен өстәргә;

20 пунктта:

алтынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

унөченче абзацта «шул исәптән суд карары яки суд боерыгы белән (ул булганда) яки алимент түләү турында нотариаль расланган килешү тәкъдим итү юлы белән» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

хәбәрсез югалган дип танылган яки үлгән дип игълан ителгән кешеләр турында;

мөрәҗәгать итүченең һәм (яисә) аның гаилә әгъзаларының эзләнелүдә булуы турында;

алимент түләү турында нотариаль расланган килешү;

баланы дәвалауга федераль бюджет, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары, җирле бюджетлар һәм башка чыганаклар хисабына түләнә торган бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм турында;

айлык пособие билгеләү турында гаризада күрсәтелгән яшәү урыны (фактик яшәү урыны) адресы буенча яшәүне өстәмә рәвештә раслаучы документлар (мәгълүматлар):

а) гариза бирүче тарафыннан торак урынын арендалау килешүе;

б) айлык пособие билгеләү турында гариза бирелгән баланың мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә йөрүе турында белешмә;

в) аңа карата пособие билгеләү турында гариза бирелгән баланың гомуми белем бирү учреждениесенә, һөнәри белем бирү оешмасына яки югары белем бирү оешмасына йөрүе турында белешмә;

24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт яки муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы башка органнар карамагында булган һәм айлык пособиене билгеләү яки яңартып җибәрү өчен кирәкле документлар (белешмәләр) сыйфатында мөрәҗәгать итүче (вәкил) түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырырга хокуклы:

туу турында – Федераль салым хезмәтеннән;

баланың үлеме турында – Федераль салым хезмәтеннән;

гаилә әгъзасының үлеме турында – Федераль салым хезмәтеннән;

өйләнешү (аерылышу) турында – Федераль салым хезмәтеннән;

баланы опекага алу турында опека һәм попечительлек органы карарындагы мәгълүматлар – Россия социаль фондыннан;

үзләренә карата гариза бирелгән баланың (балаларның) опекуны (попечителе) турында – Россия социаль фондыннан;

ата-航аналык хокукыннан мәхрүм итү (чикләү, торгызу) турында, ата-ана хокукларындагы чикләүләрне гамәлдән чыгару турында, гомеренә яки сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда баланы йолып алу турында – Россия социаль фондыннан;

ата-ананың яки баланың башка законлы вәкиленең хокукка сәләте чикләнгән булуы яисә хокукка сәләтсез дип танылуы турында – Россия социаль фондыннан;

хезмәт яисә башка бурычларны, кызыксындыру характерындагы түләүләрне дә кертеп, бүләкләү, башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт өчен бүләкләү, граждан-хокукый шартнамә кысаларында, шул исәптән түләүле шартларда опека һәм попечительлек гамәлгә ашыру турында шартнамә (тәрбиягә бала алган гаилә турында шартнамә, патронат гаилә турында шартнамә) (шул исәптән салым тотып калынган) буенча гамәл кылган өчен алынган түләү турында – Федераль салым хезмәтеннән;

ирекле формированиеләрдә торган хәрби хезмәткәрләрнең, гражданнарның, Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәү органнары, Россия Федерациясе таможня органнары, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсе хезмәткәрләре керемнәре турында белешмәләр – Федераль салым хезмәтеннән;

пенсия, пособиеләр һәм башка шундый ук түләүләр, шул исәптән мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча һәм Россия Федерациясе законнары һәм (яисә) Россия Федерациясе субъекты законнары нигезендә алынган компенсация характерындагы түләүләрнең суммалары турында – Россия социаль фондыннан;

Россия Федерациясенең мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе турында законнарында каралган очракларда вафат булган иминиятләштерелгән затларның хокукый варисларына түләүләр турында – Россия социаль фондыннан;

җан башына исәпләгәндә уртача керемен исәпләү чорында эшкә сәләтсез затларны карау турында – Россия социаль фондыннан;

гариза бирү вакытына һәм (яки) гаиләнең җан башына исәпләгәндә кереме исәпләнгән чорда эшсез яки эш эзләүче статусы булуы турында – Хезмәт һәм мәшгульлек федераль хезмәтеннән;

кыйммәтле кәгазьләр белән операцияләр һәм җитештерү финанс инструментлары белән операцияләр (тотылган чыгымнарны исәпкә алып) буенча алынган дивидендлар, процентлар һәм башка керемнәр турында, шулай ук оешма белән идарә итүдә катнашуга бәйле рәвештә дә – Федераль салым хезмәтеннән;

кредит учреждениеләренә кертемнәр буенча алынган процентлар турында – Федераль салым хезмәтеннән;

эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүләрдән алынган керемнәр, крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат төземичә хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәр һәм шәхси практика башкарудан алынган керемнәр турында – Федераль салым хезмәтеннән;

«һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллану кысаларында алынган керемнәр күләме турында белешмәләр – Федераль салым хезмәтеннән;

авторлык заказы, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә аерым хокукны читләштерү турындагы килешүләр һәм лицензия шартнамәләре буенча алынган керемнәр турында – Федераль салым хезмәтеннән;

күчемсез милекне сатудан салым салына торган керемнәр, шулай ук милекне арендага бирүдән (наем, поднаем) кергән керемнәр турында – Федераль салым хезмәтеннән;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында булган күчемсез мөлкәт турында (шул исәптән арест салынган) – Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтеннән;

Россия Федерациясе гражданинының Россия Федерациясе чикләрендә яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлүе турында – Россия Эчке эшләр министрлыгыннан;

Россия Федерациясе территориясендә Россия Федерациясе гражданинының шәхесен таныклый торган, Россия Федерациясе гражданинына элек бирелгән паспортлар турында – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан;

алына торган алиментлар турында (әгәр акчалар түләттерүчегә суд приставлары бүлегенә алиментлар түләттерүгә бәйле эш буенча вакытлыча идарәлеккә күчә торган акчаларны исәпкә алу счетыннан күчерелгән булса) – Россия Суд приставлары федераль хезмәтеннән;

автотранспорт яки мототранспорт чаралары турында – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан;

чыгарылу елы 5 елдан да артмаган кече үлчәмле су суднолары турында – Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать афәтләре нәтиҗәләрен бетерү министрлыгыннан;

гаиләнең җан башына исәпләгәндә уртача кереме исәпләнә торган чорга мөрәҗәгать итүчене яки аның гаилә әгъзаларын иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат итү турында – Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтеннән;

гариза бирүченең гаилә әгъзаларының иректән мәхрүм итү урыннарында булуы турында – Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтеннән;

инвалидлык булуы (булган очракта) һәм аның төркеме турында – Россиянең социаль фондыннан;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканы дәүләт теркәвенә алу кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 21 сентябрендәге 1507 номерлы карары белән расланган Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканы дәүләт теркәвенә алу кагыйдәләре нигезендә теркәлгән үзйөрешле машиналар һәм башка төр техника турында – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгыннан;

гариза бирүчегә һәм (яки) аның гаилә әгъзаларына карата сак астына алу яки өй аресты* рәвешендә чикләү чарасы куллану турында мәгълүмат – Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтеннән;

табигый бәла-казага яки башка гадәттән тыш хәлләргә бәйле рәвештә, шулай ук террорлык акты белән бәйле рәвештә федераль бюджет, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары, җирле бюджетлар һәм башка чыганаклар акчалары исәбеннән түләнә торган бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм суммалары турында – мондый түләүләрне түләүгә вәкаләтле булган Россия Федерациясе субъекты башкарма органыннан;

йөклелек белән бәйле рәвештә медицина оешмасында исәпкә кую, шулай ук бала тудыру яисә йөклелекне өзү турында – Россия социаль фондыннан;

«күпбалалы» гаилә статусы турында – Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнарыннан;

лотереяны оештыручылар, тотализаторлар тарафыннан һәм хәтәрлеккә нигезләнгән башка уеннардан түләнә торган, отыш нәтиҗәсендә алынган керемнәр турында – Федераль салым хезмәтеннән;

мөрәҗәгать итүчене һәм (яисә) аның гаилә әгъзаларын Россия Федерациясе законнары нигезендә Россия Федерациясенең төп аз санлы халыкларына кертү һәм традицион яшәү рәвешен алып баруы турында – Милләтләр эшләре буенча федераль агентлыктан;

хезмәт эшчәнлеге турында – Россия социаль фондыннан.»;

27 пунктта:

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мөрәҗәгать итүченең һәм (яисә) аның гаилә әгъзаларының түбәндәге күчемсез мөлкәт объектлары, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының гомуми өлеш милкендәге мөлкәтләре булу (опекадагы (попечительлектәге) балалар милегендәге күчемсез мөлкәт объектларыннан (аларның өлешләреннән), җыеп исәпләгәндә барлык гаилә әгъзаларына күчемсез мөлкәткә карата гомуми өлешле милекчелек өлеше аның гомуми мәйданының өчтән береннән азрак булган яки шуңа тигез өлешләрдән, арестта булган һәм (яки) аларга карата теркәү гамәлләре тыелган күчемсез мөлкәт объектларыннан (аларның өлешләреннән) тыш):»;

унбишенче абзацта «шәһәр округлары составындагы муниципаль берәмлекләр булмаган» сүзләрен алып ташларга;

*«яки өй аресты» сүзләре өлешендәге үзгәреш 2024 елның 1 июненнән үз көченә керә.

егерме икенче абзацны түбәндәге редакциядә җөмлә белән тулыландырырга:

«Әлеге пунктны куллану максатында опекада (попечительлектә) булган 18 яшькә кадәрге балаларга ачылган банклардагы номиналь счетлар буенча процентлар рәвешендә керемнәр исәпкә алынмый;»;

егерме алтынча абзацта «гаилә әгъзалары» сүзләреннән алда «23 яшьтән кечерәк» сүзләрен өстәргә;

утыз беренче абзацта «сак астында» сүзләреннән соң «яки өй аресты» сүзләрен өстәргә;

утыз алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кагыйдәләрнең 5 һәм 7 пунктлары нигезендә билгеләнгән айлык пособиенең җыелма күләме айлык пособие билгеләү турында гариза бирелгән балаларга һәм (яисә) мөрәҗәгать итүчегә карата уртача керемне бәяләүне исәпкә алып бирелә торган социаль ярдәм чараларының җыелма күләменнән азрак;»

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«гариза бирүченең һәм (яки) аның гаиләсенең эшкә сәләтле әгъзасының (18 яшькә кадәрге балалардан тыш) Кагыйдәләрнең 47 пунктының «н» пунктчасында каралган кереме түбәндәндәгеләрдән азрак:

Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән минималь хезмәт хакының ике тапкырга арттырылган күләменнән, әгәр гражданин салым органында һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәптә торса, Кагыйдәләрнең 48 пунктында каралган исәп-хисап чорының һәр аенда;

Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән хезмәткә минималь түләүнең 12гә бүленгән һәм гражданин һөнәри керемгә салым түләүче буларак салым органында исәптә торган, Кагыйдәләрнең 48 пунктында каралган исәп-хисап чорына туры килә торган айлар санына тапкырланган күләменең икеләтелгән дәрәҗәсеннән, гражданин һөнәри керемгә салым түләүче буларак салым органында 12 айдан азрак исәптә торган очракта.

Әлеге пунктның утыз җиденче абзацы нигезләмәләре мөрәҗәгать итүчегә һәм (яки) аның хезмәткә сәләтле гаилә әгъзасының Кагыйдәләрнең «а», «б» (пенсияләр өлешендә), «в» (медицина күрсәткечләре буенча академик отпускта булган чорда стипендияләр һәм компенсация түләүләре өлешендә), «е», «к», «м», «о» һәм «р» пунктчаларында каралган керемнәре булмаганда кагыла, Кагыйдәләрнең 48 пунктында каралган, Кагыйдәләрнең 31 пунктының «л» пунктчасында икенче-унөченче абзацларында күрсәтелгән исәп-хисап чорына туры килә торган (җыеп исәпләгәндә) очраклар искәрмә булып тора.»;

34 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«34. Айлык пособиене билгеләү турындагы гаризада һәм мөрәҗәгать итүче тапшырган документларда (белешмәләрдә) төгәл булмаган һәм (яки) тулы булмаган мәгълүматлар булуы ачыкланган очракта, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан айлык пособиене билгеләү турындагы гаризада айлык пособие инде билгеләнгән балаларга карата пособие билгеләү кирәклеге турында тамга ясалган факт, мөрәҗәгать итүчедә Россия Федерациясе территориясендә яшәү (тору) урыны буенча мөрәҗәгать итүче тарафыннан айлык пособие билгеләү турындагы гаризада фактта яшәү адресы күрсәтелгән факт ачыкланган очракта, айлык пособиене билгеләү һәм түләүне гамәлгә ашыручы орган айлык пособиене билгеләү турында

мондый гаризаны һәм документларны (белешмәләрне), төзәтелергә тиешле мәгълүматны күрсәтеп, эшләп бетерү өчен мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирергә хокуклы.»;

51 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Ирегеннән мәхрүм ителгән йөкле хатын-кызлар төзәтү учреждениесе яки тикшерү изоляторы администрациясе аша йөкле хатын-кызга айлык пособие бирү турында гариза бирә алалар.»;

түбәндәге эчтәлекле 51[1] пунктын өстәргә:

«51[1]. Айлык пособиене билгеләү турында гариза Россия Федерациясе субъектында тору урыны яки фактта яшәү урыны буенча бирелгән булса, ул айлык пособиене билгеләү турында гариза бирү мизгеленә айлык пособие элегрәк билгеләнгән яки билгеләнгән Россия Федерациясе субъекты булып тормаса, айлык пособиене билгеләү һәм түләүне гамәлгә ашыручы орган айлык пособиене билгеләү турында гариза бирелгән Россия Федерациясе субъектын түбәндәгеләр булган икенче Россия Федерациясе субъекты белән чагыштыра:

а) мөрәҗәгать итүче һәм (яки) аның хатыны (ире) керемнәреннән салым түләүләрен түләтүче салым агенты бар;

б) мөрәҗәгать итүчегә һәм (яки) аның хатынына (ире) социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме билгеләнгән;

в) мөрәҗәгать итүчегә һәм (яки) аның хатынына (ире) эшсезлек буенча пособие билгеләнгән;

г) 18 яшенә кадәрге инвалид бала яки балачактан ук I төркем инвалид яши, аңа карата мөрәҗәгать итүче һәм (яки) аның хатыны (ире) аны Россия Федерациясе Президентының «Инвалид балаларны һәм I төркем балачактан инвалидларны тәрбияләүче затларга айлык түләүләр турында» 2013 елның 26 февралендәге 175 номерлы указы нигезендә аларны тәрбиялиләр, яки I төркем инвалид, яки дәвалау оешмасыннан бәяләмә буенча даими карауга мохтаҗ булган өлкән яшьтәге кеше яисә 80 яшенә җиткән кеше яши, аңа карата мөрәҗәгать итүче һәм (яки) аның хатыны (ире) аны Россия Федерациясе Президентының «Хезмәткә сәләтсез гражданнарны караган затларга компенсация түләүләре турында» 2006 елның 26 декабрендәге 1455 номерлы указы нигезендә карыйлар;

д) гариза бирүче һәм (яки) аның хатыны (ире) күпбалалы гаилә статусына ия;

е) мөрәҗәгать итүчегә һәм (яки) аның хатынына (иренә) Россия Федерациясе субъекты законнары нигезендә торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә социаль ярдәм чаралары билгеләнгән;

ж) мөрәҗәгать итүче һәм (яки) аның хатыны (ире) Россия Федерациясенең төньягында, Себерендә һәм Ерак Көнчыгышындагы аз санлы җирле халыкларга караган кешеләр буларак традицион яшәү рәвеше алып баралар һәм традицион хуҗалык эшчәнлеген алып баралар;

з) мөрәҗәгать итүчегә һәм (яки) аның хатынына (иренә) картлык, туендыручысын югалту яки инвалидлык буенча пенсияләр билгеләнгән.

Айлык пособие билгеләү турында гариза бирелгән Россия Федерациясе субъекты Кагыйдәләрнең 20(1) пунктында күрсәтелгән фактларның берсе билгеләнгән Россия Федерациясе субъекты белән туры килсә, Кагыйдәләрнең 20(1)

пунктында күрсәтелгән башка фактлар буенча Россия Федерациясе субъектлары туры килмәсә, айлык пособие Кагыйдәләр нигезләмәләренә ярашлы билгеләнә ала.

Кагыйдәләрнең 20(1) пунктында күрсәтелгән барлык фактлар турында мәгълүмат булмаган очракта яки айлык пособие билгеләү турында гариза бирелгән Россия Федерациясе субъекты айлык пособие билгеләүне һәм түләүне гамәлгә ашыручы орган шундый фактларның берсе билгеләнгән Россия Федерациясе субъекты белән туры килмәгән очракта, Россия Федерациясе субъектлары әлеге пунктка ярашлы рәвештә чагыштырылганнан соң 1 эш көне эчендә Бердәм портал аша мөрәҗәгать итүчегә Кагыйдәләрнең 26 һәм 27 пунктларында билгеләнгән срокларда айлык пособие билгеләү турында гаризада күрсәтелгән яшәү урыны (фактик яшәү урыны) адресы буенча яшәүне өстәмә рәвештә раслаучы документларның (мәгълүматларның) берсен тапшыру зарурлыгы турында белдерү ясала.».